| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 декабрь г.Бугульма № 1463

## “2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районының янгын куркынычсызлыгы” максатчан программасын раслау турында

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69 номерлы Россия Федерациясе Законының 3 һәм 19 маддәләрен тормышка ашыру һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында, янгын чыгу куркынычын киметүгә, һәлак булган һәм зыян күргән кешеләр санын киметүгә, аларга китерелгән матди зыяннарны киметүгә, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең һәм ирекле янгын оешмаларының хәрби әзерлеген күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар турында **Карар кабул итәм:**

1. “2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районының янгын куркынычсызлыгы” максатчан программасын расларга (Кушымта №1).

2. Бөгелмә муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:
“2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районының янгын куркынычсызлыгы” максатчан программасында каралган чараларның үз вакытында үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Бөгелмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә:
ел саен, чираттагы финанс елына Бөгелмә муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, "2017-2019 елларга Бөгелмә муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы" максатчан программасы чараларын тормышка ашыруга акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары В. Гарәфетдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Галиуллин